**Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение**

**«Усть-Туркская средняя общеобразовательная школа» Бажуковский филиал**

| | |
|---|---|
| СОГЛАСОВАНО<br>Заместитель директора по УВР<br>_________/ Аитова Э.Р.<br>«30» августа 2024 г. | УТВЕРЖДЕНО<br>Директор<br>МАОУ «Усть-Туркская СОШ»<br>_________/ Юсупова И.Ф.<br>Приказ №123 от<br>«30» августа 2024 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**курса внеурочной деятельности**

**«Хочу всё знать по татарскому языку»**

для обучающихся 9го класса

**с. Бажуки, 2024г.**

## Аңлатма язуы

«Татар теленнән барысын да белергә телим» электив курсы өчен 34 сәгатьлек махсус программа тел белеменең барлык тармакларын үз эченә алган. Эчтәлеге үзенчәлекле, укучыларда телне үзләштерүгә кызыксыну һәм эчке омтылыш формалаштыруга юнәлтелгән.

Хәзерге татар әдәби тел нормаларын телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану үзенчәлекләрен төшендерү өчен уйланылган. Тел белеме бүлекләренең кыен очракларына игътибар бирелгән. Сүзләргә фонетик, лексик, морфологик анализ ясау тәртибе; сүз төзелеше һәм ясалышы; ситаксис һәм пунктуациягә дә урын бирелгән. Алган белемнәрне ныгыту һәм эзлеклелеккә салырга, аны гамәли куллана алу мөмкинчелеген арттырырга җирлек тудырылган. Орфографик, орфоэпик таләпләр үтәлеше дә язма һәм телдән сөйләм күнекмәләрендә ныгыту күздә тотылган. Ә бүгенге көндә тирән белемле һәм грамоталы укучы - конкурентлыкка омтылучыларның берсе булып тора. Татар теле әдәби тел, камил тел булуын укучылар төшенә, аңлый. Тел белеменең ,,энҗе бөртекләре,сәйләннәре"- безнең сүзлек хәзинәбез. Ә бу курс телне тагын да чарларга, камилләштетергә омтылыш тудыра. Укучы үз телен камил белгән очракта гына башка тел грамматикасын ныклап өйрәнүгә мөмкинчелек туа. Бу курс татар телебезгә, халкыбызның тарихына һәм мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләргә, укучы балаларда милли үзаң формалаштырырга, телнең үзенчәлекле якларын тирәнрәк үзләштерергә, имтиханнарны уңышлы бирергә ярдәм итәр.

9 нчы сыйныф укучылары, узган сыйныфларда алган белемнәренә таянып, тел ярдәмендә төп мәдәни кыйммәтләрне өйрәнәләр. Югары сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты фәнен тыгыз бәйләп алып бару, ягъни интеграцияләп укыту зарурлыгы туа. Мәгълүм булганча, тел дәресләрендә укучылар һәрвакыт мисаллар (нинди дә булса текст) белән эш итә. Алар дәреслектәге күнегүләрдә бирелгән. Шуларга өстәп, укытучы үзе сайлаган, тагы да уңышлырак дип исәпләнгән текстларны да тәкъдим итә ала. Әлбәттә, бу текстлар тел күренешен яхшырак аңларлык, шәфкатьлелек, милли патриотизм һәм толерантлык рухында тәрбияләрлек булырга тиеш.

Программада тел белеменең грамматик чараларын уңышлы файдалану максаты күздә тотылды. Укучыларның сөйләм һәм язу күнекмәләрен камилләштерүгә ярдәм итә. Укучылар алынган белемнәрен сөйләм практикасында, сочинение һәм изложениеләр язганда, БДИ биремнәренә әзерләнгәндә һәм аларны үтәгәндә кулланырга тиеш.

**Максаты:**

- укучыларны татар теленнән имтиханга әзерләү;

**Бурычлары:**

- татар теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрне системалаштыру;
- телнең төп грамматик чараларын язма һәм телдән сөйләм процессында куллануга ирешү;
- укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилли белергә күнектерү;
- татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга , аларны тиешенчә куллана белергә өйрәтү;
- текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны таба белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу;
-орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү;
-укучыларның игътибарын телнең эстетик функциясен чагылдыручы әдәби текстка, өйрәнелә торган тел күренешләренең сәнгатьлелек ягына юнәлтү;
- балалар туган телнең матурлыгын күрергә һәм ишетергә өйрәнсеннәр, нинди сурәтләү чаралары аша аның тормышка ашырылуын аңласыннар өчен телнең тасвирлау һәм сурәт ясау мөмкинлекләрен күрсәтү, телнең җанлы халәтен, кулланылыш рәвешен өйрәнеп, сүз белән сөйләм арасындагы бәйләнешнең нигезенә ныграк төшенергә , әдәби әсәрдә һәм автор сөйләмендә сүзнең тәмен, ямен, матурлыгын тоярга, үз сүзен, фикерен әйтә белергә өйрәтү.
-әдәби тел нормаларын күнекмәләрдә дөрес куллана алуга өйрәтү, иҗадилыкка омтылу.

**Эчтәлеге**

«Татар теленнән барысын да белергә телим» электив курсы төрле текстлар белән тирәнтен эшләүне, имтиханнарга әзерләнү һәм татар теле, әдәбияты юнәлешендә югары уку йортларына кергәндә ярдәм итүне күздә тотып төзелде. Атнага бер сәгать, ел буена 34 сәгать исәбе буенча үткәрелә.

**Коммуникатив компетенция**

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре (тыңлап аңлау,сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) үзләштерелә. Укучылар тыңланган яки укылган текстның темасын, төзелешен һәм төп фикерен, жанрын ачыклый, текст буенча әңгәмә үткәрә, үз фикерен дәлилли, телнең орфографик һәм орфоэпик, лексик, морфологик, синтаксик нормаларын саклап, телдән яки язмача эчтәлеген кыскача, тулы, сайлап алып җиткерә. Телнең әдәби нормаларын саклап, төрле темаларга диалогик һәм монологик сөйләм оештыра. Төрле типтагы язма эшләр, шул исәптән хат, сочинение, тестлар һ.б. эшләр башкара. Татар сөйләм этикеты нормаларын дөрес һәм урынлы куллана.

***Лингвистик компетенция***

Татар теленең иҗтимагый-мәдәни роле; татар милли әдәби теле һәм аның төп орфографик, орфоэпик нормалары; телнең фонетик системасы һәм закончалыклары; иҗек, татар теленең иҗек калыплары; басым, интонация  һәм аларның төрләре; орфография һәм орфоэпия.

***Этнокультура өлкәсенә караган компетенция***

Тел чаралары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләрен өйрәнү; тәкъдим ителгән текстлардан халык авыз иҗаты үрнәкләрен, тарихи лексиканы аеру, аларның төрләрен һәм мәгънәләрен өйрәнү.

## Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр

9нчы сыйныфта татар теле предметын өйрәтү тел берәмлекләрен таный, аңлый, анализлый белү күнекмәләре белән бергә, сөйләм культурасын үстерүне, төрле типтагы мәгълүматны, сөйләм ситуациясенә карап, дөрес һәм төгәл итеп башкаларга җиткерә алуны, татар теленең әдәби һәм сөйләм этикеты нормаларын үтәүне дә бурыч итеп куя.

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- акыл, мөстәкыйль фикерләү эшчәнлеген активлаштыру;
- үзеңне тәрбияләү, үзең белән идарә итү, үз фикереңне яклый алу сәләтен үстерү;
- сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен аңлау;

**Курсны үзләштерү барышында ирешергә тиешле нәтиҗәләр:**

- телдән һәм язма сөйләм, диалог һәм монолог, аралашу ситуациясе, тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- төрле стиль һәм жанрдагы текстларны сәнгатьле итеп уку күнекмәләре булдыру;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача сөйләп бирү, текст буенча куелган сорауларга төгәл җавап бирү;
- тормыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикерекңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби нормаларын (орфографик, орфоэпик, лексик, грамматик, пунктацион) саклау һәм сөйләм этикеты нормаларын үтәү;

***Предметара нәтиҗәләр:***

- татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләрендәге тәэсир көчен, сәнгатьлелеген булдырудагы ролен ачыклау;
- телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- татар телен рус теле белән бәйләп, телләр һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә – рухи кыйммәтләргә ихтирам, башка милләт вәкилләренә карата түземле-ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;
- телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, аның үсеше турында күзаллау формалаштыру;
- телнең кеше һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын аңларга ярдәм итү.

**Календарь-тематик план**

| № | Курсның темасы | Сәгатьләр саны | Вакыты | Эш формасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш. Түгәрәк курсының эчтәлеге белән танышу. Куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру. Тел дигән дәрья бар. | 1 | 06.09. | әңгәмә |
| 2 | Татар теленнән БДИ бирүгә әзерлек.имтихан бирүгә төп таләпләр | 1 | 11.09. | әңгәмә, презентация карау |
| 3 | 1 нче өлеш буенча аңлату, иҗади эшләү | 1 | 18.09. | аудиотасманы тыңлау |
| 4 | 2 нче өлеш буенча аңлату, иҗади эшләү | 1 | 25.09. | презентация карау |
| 5 | 3 нче өлеш буенча аңлату, иҗади эшләү | 1 | 02.10. | презентация карау |
| 6-7 | 4 нче өлеш буенча аңлату. Шәхси хат язарга өйрәнү. Хат язуга таләпләр | 2 | 09.10.<br>16.10. | презентация карау<br>хат язу |
| 8-9 | ТОГЭ эшен башкарырга өйрәнү | 2 | 23.10.<br>06.11. | биремнәрне үтәү |
| 10-11 | Фонетика һәм орфоэпия. Аваз һәм хәрефләр, сузык авазлар Тартык авазлар. Аларның квалификациясе | 2 | 13.11.<br>20.11. | сорау-җавап, күнегүләр эшләү |
| 12-13 | Сузык һәм тартык авазлар өлкәсендәге үзгәрешләр | 2 | 27.11.<br>04.12. | сорау-җавап, күнегүләр эшләү |
| 14- | Фонетика буенча тестлар эшләү | 2 | 11.12.<br>18.12. | тест биремнәрен үтәү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15 | | | | |
| 16-17 | БДИ биремнәрен күмәк, парлы үтәү. | 2 | 25.12<br>25.12 | биремнәрне үтәү, нәтиҗә ясау |
| 18-19 | Графика, орфография. Сузык һәм тартык аваз хәрефләренең дөрес язылышы | 2 | 08.01.<br>15.01. | практикум |
| 20-21 | ъ ,ь билгеләренең дөрес язылышы. Кушымчаларның дөрес язылышы | 2 | 22.01.<br>29.01. | практикум |
| 22-23 | Морфемика һәм сүз ясалышы. Сүзнең мәгънәле кисәкләре, сүзнең тамыры һәм нигезе | 2 | 05.02.<br>12.02. | сорау-җавап, күнегүләр эшләү |
| 24-25 | Кушымчалар һәм аларның төрләре Тестлар эшләү | 2 | 19.02.<br>26.02. | практикум |
| 26-27 | Морфология. Сүз төркемнәре Мөстәкыйль сүз төркемнәре | 2 | 05.03.<br>12.03. | практикум |
| 28-29 | Бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәре | 2 | 19.03.<br>02.04 | практикум |
| 30-31 | Синтаксис. Пунктуация. Гади һәм кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.<br>Синтаксик анализ | 2 | 09.04.<br>16.04. | презентация карау |
| 32 | Тиңдәш кисәкләр. Аерымланган хәлләр янында тыныш | 2 | 23.04. | күнегүләр, тестлар эшләү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| -<br>33 | билгеләре. Тест эшләү | | 30.04. | |
| 34 | Эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау, йомгаклау | 1 | 07.05. | эшкә йомгак ясау |
| **Барысы: 34 сәг.** | | | | |

**Белем һәм күнекмәләр. Көтелгән нәтиҗә.**

Электив курс үткәннән соң укучылар белергә тиеш:

а) үз сөйләмеңдә төрле грамматик кагыйдәләрне урынлы куллана белү;

ә)үзеңнең сөйләмеңдә һәм янәшәңдә булганнарның сөйләм кимчелекләрен күрә һәм төзәтә белү.

в)алган белемнәрне практикада куллана алу.

г) имтиханны уңышлы бирү

**Әдәбият**

1.Бердәм Республика имтиханына әзерләнәбез. Татар теле. Татар мәктәпләре һәм рус телле мәктәпләрнең татар сыйныфлары өчен. Школа, Казан, 2007.

2. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика. Укытучылар өчен кулланма Казан, «Мәгариф», 2002.

3. Вәлиева Ф.С, Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Казан, «Раннур», 2002.

4. Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлары өчен. Укытучылар өчен кулланма. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2006;

5. Максимов .Н. В. Татар теленнән тестлар. Уку-укыту ярдәмлеге. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2008;
6. Максимов Н. В. Урта мәктәптә татар телен укыту. Укытучылар өчен кулланма. Казан, «Мәгариф». 2004.
7. Сафиуллина Ф.С, Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Урта һәм югары уку йортлары өчен дәреслек,Казан, «Мәгариф», 2002.
8. Татар әдәбияты. Теория. Тарих. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2006.
9. Татар теленнән бердәм Республика имтиханына әзерләнәбез. Татар мәктәпләре һәм рус мәктәпләренең татар сыйныфлары өчен кулланма. Школа, Казан, 2008.
10.Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары. 5-11 нче сыйныфлар. Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2010.
11. Язма эшләр җыентыгы. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 9 нчы сыйныфында укучы татар балаларына ана теленнән язма имтиханга әзерләнү һәм аны үткәрү өчен текстлар. Казан, "Мәгариф" нәшрияты, 2004.